КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 апрель г.Казань № 203

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1079 нчы карары белән расланган 2018 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1079 нчы карары белән расланган 2018 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекнең 6.1 пунктында:

6.1.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7) «Җылыга чыдамлы савыт-саба һәм җылыга чыдамлы боросиликат пыяладан эшләнмәләр җитештерү буенча технологик линияләр белән пыяла эретү мичен яңарту һәм техник яңадан коралландыру» («Васильево пыяла заводы» АҖ, Зеленодольск муниципаль районы).»;

6.1.9 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«7) «Россиядә Haier кер юу машиналарын җитештерүне оештыру» («ХАЙЕР ЛАУНДРИ МАШИН РУС» ҖЧҖ, Чаллы ш.);

8) «Россиядә Haier кер юу машиналарын җитештерү проекты» («ХАЙЕР ЛАУНДРИ МАШИН РУС» ҖЧҖ, Чаллы ш.).»;

6.1.13 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«5) «Алексеевск муниципаль районында йөк елга порты төзелеше» («Автострада» АЖ, Алексеевск муниципаль районы);

6) «Кама Тамагы т.п. районында 1 номерлы флот базасы. Төзелеш» («Транснефть-Прикамье» АЖ, Кама Тамагы муниципаль районы).»;

6.1.17 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«24) «Химград» технополисы территориясендә тоташ тирәлекләр чыгымын, күләмен үлчәү чараларын җитештерүне оештыру» («Ирвис» ФҖБ ҖЧҖ, Казан ш.);

25) «Теләче» сәнәгать паркы төзелеше» («Созидание» идарә компаниясе» ҖЧҖ, Теләче муниципаль районы).»;

6.1.5 пунктчаның унынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6.1.7 пунктчаның өчнече абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 бүлекнең 6.2 пунктында:

6.2.5 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«8) «Азык-төлек продуктларын, гигиена товарларын һәм балалар ризыкларын төрү өчен яхшыртылган эксплуатация һәм экология сыйфатлары белән пленка материаллар җитештерүне киңәйтү» («ДАНАФЛЕКС-НАНО» ҖЧҖ, Казан ш.).»;

6.2.6 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«3) «Татар-Шатрашан цеолитлы токымнар чыганагын эшкәртү һәм товар продукциясе җитештерүне оештыру» («Идел буе цеолитлары» ААҖ, Чүпрәле муниципаль районы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин